**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «30» маеннан № 23-180

2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт һәм балалар мәйданчыкларыннан рациональ һәм нәтиҗәле файдалану һәм 2022 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың 2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт һәм балалар мәйданчыкларыннан рациональ һәм нәтиҗәле файдалану һәм 2022 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың 2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт һәм балалар мәйданчыкларыннан рациональ һәм нәтиҗәле файдалану һәм 2022 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә:

- ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең спорт мәйданчыкларын өстәмә җиһазлар белән тәэмин итүгә грант эшчәнлегендә катнашуын көчәйтергә;
- каникуллар вакытында төзелгән спорт һәм балалар мәйданчыкларында мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре белән берлектә чаралар оештырырга;
- 2022 елда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче район халкы санын 54,3 %ка кадәр җиткерүгә ирешергә;
- спорт мәктәпләрендә сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итәргә, район һәм республика ярышларында катнашу өчен җыелма командаларны әзерләргә һәм комплектларга;

- ял итү урыннарында, спорт базаларында, спорт мәйданчыкларында һәм башка спорт объектларында халыкны физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнү өчен шартлар тудырырга;

- Идел буе Болгарының 1100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган спорт чараларын үткәрүне оештырырга.

3. Универсаль спорт мәйданчыкларын балансларында тотучыларга:

- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү, шулай ук профилактик эшләр һәм УСПны төзекләндерү буенча эшләр башкару өчен спорт мәйданчыкларына кешеләрне (барлык категорияләрне) кертү мөмкинлеген оештырырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов